МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

20.12.2021 г.Казань № 946

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 10 февралендә 8882 номеры белән теркәлде

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының
20.12.2021 №946 боерыгы белән
расланды

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә нурланыш авыруы һәм радиация йогынтысына яки техноген һәлакәтләрнең нәтиҗәләрен бетерү эшләренә бәйле башка авырулар алган яки кичергән гражданнарга, техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендәге инвалидларга таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 16 июлендәге 566 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 11.07.2016 №394, 08.06.2017 №348, 07.05.2018 №357, 19.09.2018 №887, 26.07.2019 №580, 15.11.2019 №1031, 14.07.2020 №518, 09.10.2020 №715 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә нурланыш авыруы һәм радиация йогынтысына яки техноген һәлакәтләрнең нәтиҗәләрен бетерү эшләренә бәйле башка авырулар алган яки кичергән гражданнарга, техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендәге инвалидларга таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1.4.1 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» дәүләт мәгълүмат системасында (http://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы)» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы

Чернобыль һәлакәте яки Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәләрен бетерү эшләренә бәйле рәвештә нурланыш авыруын алган һәм радиация йогынтысына бәйле башка авыруларны алган яисә кичергән гражданнарга, Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендә инвалидларга таныклык (таныклык дубликаты) (алга таба – таныклык (таныклык дубликаты)) бирү.

2.2. Башкарма хакимият органы исеме

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районында яки шәһәр округындагы Социаль яклау идарәсе (бүлеге) исеменнән Татарстан

Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып таныклык (таныклык дубликаты) бирү яисә таныклык (таныклык дубликаты) бирүдән баш тарту турында карар тора.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) чоры

2.4.1. Таныклыкны бирү (таныклык бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар белән гариза теркәлгәннән соң 15 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча документлар соратып алу зарурлыгы булганда, дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты документлар белән гаризаны теркәгәннән соң 20 эш көненә кадәр озайтыла.

2.4.2. Мөрәҗәгать итүчегә таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турында карар Министрлыктан Идарәгә (бүлеккә) алынган көнне гамәлгә ашырыла.

2.4.3. Таныклык (таныклык дубликаты) һәм (яки) таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турында карар күчермәсен таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар хакында хәбәр ителгән мөрәҗәгать итүчегә тапшыру мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

2.4.4. Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе

2.5.1. Таныклыкны алу өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләрне тапшыра:

Чернобыль һәлакәте («Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт) аркасында яки Чернобыль АЭС һәлакәт («Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт) нәтиҗәләрен бетерү эшләренә бәйле рәвештә нурланыш авыруын һәм башка авыруларны алган яки кичергән гражданнарга, Чернобыль һәлакәте («Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт) нәтиҗәсендә инвалид булган

гражданнарга таныклык бирү турында гариза (гаризаның киңәш ителә торган формасы әлеге Регламентка 1 нче кушымтада китерелә);

үлемне дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыкның чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе.

Әлеге Регламентның 1.2 пунктының «а»-»д» пунктларында күрсәтелгән гражданнар өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне тапшыралар:

радиоактив пычрану, эвакуация яки радиоактив пычрану зонасыннан күчерү зонасында яшәү (хәрби яки аңа тиңләштерелгән хезмәт үтү) фактынраслаучы билгеләнгән үрнәктәге таныклык яки белешмә;

Чернобыль АЭСындагы һәлакәт («Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт) нәтиҗәләрен бетерү эшендә катнашу фактын раслаучы билгеләнгән үрнәктәге таныклык;

Чернобыль һәлакәте («Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт) аркасында килеп чыккан авыруларның һәм радиация йогынтысына бәйле инвалидлыкның сәбәпле бәйләнеше турында ведомствоара эксперт советы яисә хәрби-табиблык комиссиясе бәяләмәсе;

мөрәҗәгать итүченең 3х4 см үлчәмендәге фотосы;

Әлеге Регламентның 1.2 пунктының «е» пунктчасында күрсәтелгән гражданнар өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне тапшыралар:

элегрәк бирелгән яисә Россия Федерациясе Гражданлык оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм стихияле бәла-казаларның нәтиҗәләрен бетерү эшләре министрлыгының, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының, Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2006 елның 8 декабрендәге 728/832/166н номерлы боерыгы белән расланган Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендә яки Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәләрен бетерү эшләренә бәйле рәвештә нурланыш авыруын һәм радиация йогынтысына бәйле башка авыруларны алган яки кичергән; Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендә инвалид булган гражданнарга таныклык рәсмиләштерү һәм бирү тәртибе һәм шартлары (Россия Федерациясе ГТХМ 728 номерлы боерыгы белән расланган Тәртип) нигезендә бирелгән үлгән гражданин таныклыгы;

бергә яшәү фактын раслаучы документлар (кирәк булган очракта).

Кирәкле очракларда гражданнар әлеге таныклыкны алу хокукына ия зат белән туганлык мөнәсәбәтләрен раслаучы документларны; уллыкка алу турында таныклыкны; билгеләнгән тәртиптә бирелгән таныклык алуга ышанычнамәне; шәхесне таныклаучы һәм гражданлыкка күрсәтә торган башка документларны тапшыралар.

2.5.2. Таныклык дубликатын алу өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләрне тапшыра:

Чернобыль һәлакәте («Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт) аркасында яки Чернобыль АЭС һәлакәт («Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт) нәтиҗәләрен бетерү эшләренә бәйле рәвештә нурланыш авыруын һәм башка авыруларны алган яки кичергән гражданнарга, Чернобыль һәлакәте («Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт) нәтиҗәсендә инвалид булган гражданнарга таныклык бирү турында гариза (гаризаның киңәш ителә торган формасы әлеге Регламентка 2 нче кушымтада китерелә);

мөрәҗәгать итүченең 3 х 4 см фотосы (әлеге Регламентның 1.2 пунктының «а»-»д» пунктчасында күрсәтелгән гражданнар өчен);

бозылган таныклык – бозылганы урынына алмаш таныклык алу өчен мөрәҗәгать иткән очракта.

2.5.3. Мөрәҗәгать итүчеләрнең законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итү вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.

2.5.4. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

2.5.5. Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Идарә (бүлек) белгече тарафыннан таныклана.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Идарәгә (бүлеккә) шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

2.5.6. Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Идарәгә (бүлеккә), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин; Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закондагы (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш.

2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итә торган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма

2.6.1. Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча вәкаләтле органнардан түбәндәгеләр алына:

югалган таныклыкның табылмавын раслаучы белешмә;

пенсия алу факты турында белешмәләр;

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр;

өйләнешүне дәүләт теркәвенә алу турында;

туендыручының үлеме турында белешмәләр;

шәхси счетның иминият номеры турында белешмәләр;

инвалидлык билгеләү факты турында мәгълүмат (инвалидлар өчен).

2.6.2. Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

2.6.3. Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

2.6.4. Идарә (бүлек) мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ- номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә элегрәк электрон үрнәкләре таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

шушы Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның мөрәҗәгать итүе;

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегеннән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

мөрәҗәгать итүченең яшәү урынына карамаган Идарәгә (бүлеккә) мөрәҗәгать итүе.

документларда Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерелгән, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булуы;

Идарәгә (бүлеккә) гариза һәм 63-ФЗ һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә документлар (документларның күчермәләрен) тапшыру.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезе булып дөрес булмаган (төгәл булмаган) белешмәләрдән торган документларны тапшыру тора.

## 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

## 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләр күрсәтү исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтләрен күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында да белешмәләр

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

## 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

## 2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.

2.12.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

## 2.13. Дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында мөрәҗәгать итүче гаризасын теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да

2.13.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза кирәкле барлык документлары белән гариза алынган көнне теркәлә.

2.13.2. Гариза һәм кирәкле барлык документлар электрон документлар рәвешендә ял көннәрендә яисә эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, гариза Идарәнең (бүлекнең) ял көненнән яисә эшләми торган бәйрәм көненнән соңгы беренче эш көнендә теркәлә.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.14.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) әлеге Регламентның 1.4.2 пунктының 1 пунктчасында каралган мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.14.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объектлардан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең

рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектка озата йөри торган этне кертү.

2.14.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) дәүләт хезмәте күрсәтүче органнар һәм оешмалар хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга, башка затлар белән беррәттән, дәүләт хезмәте күрсәтүгә комачаулый торган каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар, шулай ук аудиоконтур күчермәләре булу.

2.14.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән һәркемнең файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәте һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәте күрсәтү (шул исәптән тулы күләмдә) мөмкинлеге яки андый мөмкинлекнең булмавы

2.15.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең файдалана алырлык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Идарә (бүлек) бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләрен мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон рәвештә алу мөмкинлеге;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтелүе.

2.15.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

белгечләр тарафыннан Регламент бозылуга бәйле прецедентлар (нигезле шикаятьләр) булмавы;

мөрәҗәгать итүченең Идарә (бүлек) белгечләре белән бәйләнешкә керү күләме;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен кирәкле документлар турыдан-туры тапшырылганда – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар почта аша җибәрелгәндә, – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Идарә (бүлек) белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.

2.15.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.

2.15.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкның http://mtsz.tatarstan.ru сайтында, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/) алынырга мөмкин.

2.15.5. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

### 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр

Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Идарәгә (бүлеккә), «Интернет» челтәреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан Идарәгә (бүлеккә) электрон саклагычлардан

файдаланып тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закондагы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш.»;

3 нче бүлектә:

Исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәлү чорлары. Аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре»;

3.4.1 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

3.4.2 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Идарә (бүлек) белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә, шул исәптән электрон рәвештә дә, вәкаләтле органнарга түбәндәге документларны һәм белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

пенсия билгеләү турында;

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

өйләнешүне дәүләт теркәвенә алу турында;

туендыручының үлеме турында;

югалган таныклыкның табылмавын раслый торган белешмә (мөрәҗәгать итүче таныклык дубликаты сорап мөрәҗәгать иткән очракта);

шәхси счетның иминият номеры турында;

инвалидлык билгеләү факты турында.»;

3.5.1 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.1. Идарә (бүлек) белгече, әлеге Регламентның 3.4.2 пунктчасында күрсәтелгән, билгеләнгән чорда вәкаләтле органнардан алынган, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган белешмәләр (документлар) нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

түбәндәге эчтәлекле 3.10 пункт өстәргә:

«3.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.»;

5 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуын

яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.».

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга бердәй үрнәктәге махсус таныклыклар (таныклыклар дубликатларын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2012 елның 19 июлендәге 574 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 26.06.2017 №416, 15.05.2018 №366, 18.09.2018 №886, 16.04.2019 №276, 27.08.2019 №652, 12.11.2019 №984, 06.07.2020 №488, 08.10.2020 №711, 26.02.2021, 26.02.2021, 26.02.2021 №114 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга бердәй үрнәктәге махсус таныклыклар (таныклыклар дубликатларын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1.4.1 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» дәүләт мәгълүмат системасында (http://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы)» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы

Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга бердәм үрнәктәге махсус таныклыклар (таныклыкларның дубликатларын) (алга таба – таныклык (таныклык дубликаты)) бирү.

2.2. Башкарма хакимият органы исеме

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районында яки шәһәр округындагы Социаль яклау идарәсе (бүлеге) исеменнән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау

Бердәм үрнәктәге таныклык (таныклык дубликаты) бирү яки таныклык (таныклык дубликаты) бирүдән баш тарту турында карар.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия

Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) чоры

2.4.1. Таныклыкны бирү (таныклык бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар белән гариза теркәлгәннән соң 15 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

2.4.2. Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча документлар соратып алу зарурлыгы булганда, дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты документлар белән гаризаны теркәгәннән соң 20 эш көненә кадәр озайтыла.

2.4.3. Мөрәҗәгать итүчегә таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турында карар Идарә (бүлек) җитәкчесе тарафыннан имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

2.4.4. Таныклык (таныклык дубликаты) һәм (яки) таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турында карар күчермәсен таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар хакында хәбәр ителгән мөрәҗәгать итүчегә тапшыру мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

2.4.5. Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

## 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе

2.5.1. Таныклык алу өчен мөрәҗәгать итүчеләр:

Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар ителгән гражданинга бердәй үрнәкле махсус таныклык бирү турында гариза, Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә радиоактив пычранган зоналарда яшәү һәм (яки) хәрби хезмәт узу (хезмәт итү) турындагы мәгълүматларны (яшәү һәм (яки) хәрби хезмәт узу (хезмәт итү) торак пунктын, адресын, срокларын) күрсәтеп. Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән;

чит ил дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

гражданлык хәле актларын теркәү органнары яисә Россия Федерациясе консуллык учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка (кызлыкка) алу турында таныклык күчермәсе.

2.5.2. Таныклык дубликатын алу өчен мөрәҗәгать итүчеләр:

Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар ителгән гражданинга бердәй үрнәкле махсус таныклык дубликаты бирү турында гариза, анда таныклыкны югалту (бозу) шартлары һәм аны алу урыны күрсәтелә.

Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында китерелгән;

бозылган таныклык – бозылганы урынына алмаш таныклык алу өчен мөрәҗәгать иткән очракта.

2.5.3. Мөрәҗәгать итүче гариза белән мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

2.5.4. Мөрәҗәгать итүчеләрнең законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать итүчеләрнең мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтләрен раслый торган һәм мөрәҗәгать иткәндә шәхес таныклый торган документны күрсәтә.

2.5.5. Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.

2.5.6. Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Идарә (бүлек) хезмәткәре тарафыннан таныклана.

2.5.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Идарәгә (бүлеккә) шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

2.5.8. Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары таләпләренә туры китереп, электрон имза белән кул куелган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итә торган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма

2.6.1. Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча вәкаләтле органнардан түбәндәгеләр алына:

югалган таныклыкның табылмавын раслаучы белешмә;

Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиоактив пычрану зоналарында гражданинның яшәү һәм (яки) хәрби хезмәт узу (хезмәт итү) фактын раслый торган документлар;

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр;

шәхси счетның иминият номеры турында белешмәләр.

2.6.2. Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

2.6.3. Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

2.6.4. Идарә (бүлек) мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган документлар һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә электрон рәвешләре элегрәк таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту (документларны асылы буенча карамыйча кире кайтару) нигезләренең тулы исемлеге

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

Идарәгә (бүлеккә) гариза һәм 63-ФЗ һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә документлар (документларның күчермәләрен) тапшыру;

документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерелгән, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булуы;

мөрәҗәгать итүченең яшәү урынына карамаган Идарәгә (бүлеккә) мөрәҗәгать итүе.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезе булып дөрес булмаган (төгәл булмаган) белешмәләрдән торган документларны тапшыру тора.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләр күрсәтү исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтләрен күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында да белешмәләр

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.

2.12.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.13. Дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында мөрәҗәгать итүче гаризасын теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да

2.13.1. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризасы гариза һәм документлар алынган көнне теркәлә.

2.13.2. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.14.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) әлеге Регламентның 1.4.2 пунктының 1 пунктчасында каралган мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.14.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объектлардан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н

номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектка озата йөри торган этне кертү.

2.14.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) дәүләт хезмәте күрсәтүче органнар һәм оешмалар хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга, башка затлар белән беррәттән, дәүләт хезмәте күрсәтүгә комачаулый торган каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар, шулай ук аудиоконтур күчермәләре булу.

2.14.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

## 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән һәркемнең файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәте һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәте күрсәтү (шул исәптән тулы күләмдә) мөмкинлеге яки андый мөмкинлекнең булмавы

2.15.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең файдалана алырлык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Идарә (бүлек) бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында тулы мәгълүмат булуы;

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә дәүләт хезмәте күрсәтүгә комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтелүе.

2.15.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

белгечләр тарафыннан Регламент бозылуга бәйле прецедентлар (нигезле шикаятьләр) булмавы;

2.15.3. Мөрәҗәгать итүченең Идарә (бүлек) белгечләре белән бәйләнешкә керү күләме:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен кирәкле документлар турыдан-туры тапшырылганда – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар почта аша җибәрелгәндә, – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

2.15.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Идарә (бүлек) белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.

2.15.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.

2.15.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкның http://mtsz.tatarstan.ru сайтында, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/) алынырга мөмкин.

2.15.7. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

## 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр

Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Идарәгә (бүлеккә), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук электрон саклагычлардан файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Идарәгә (бүлеккә) тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закондагы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш.»;

3 нче бүлектә:

Исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре»;

түбәндәге эчтәлекле 3.10 пункт өстәргә:

«3.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.»;

5 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе».

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Семипалатинск полигонындагы атом-төш сынаулары аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 16 июлендәге 567 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 18.01.2013 №20, 07.06.2016 №317, 10.10.2016 №573, 08.06.2017 №348, 07.05.2018 №357, 19.09.2018 №887, 26.07.2019 №580, 15.11.2019 №1031, 14.07.2020 №518, 09.10.2020 №715 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Семипалатинск полигонындагы атом-төш сынаулары аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1.4.1 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» дәүләт мәгълүмат системасында (http://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы)» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы

Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга таныклык (таныклык дубликаты) (алга таба – таныклык (таныклык дубликаты)) бирү.

2.2. Башкарма хакимият органы исеме

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районында яки шәһәр округындагы Социаль яклау идарәсе (бүлеге) исеменнән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

## 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып таныклык (таныклык дубликаты) бирү яисә таныклык (таныклык дубликаты) бирүдән баш тарту турында карар тора.

## 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) чоры

2.4.1. Таныклыкны бирү (таныклык бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар белән гариза теркәлгәннән соң 11 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча документлар соратып алу зарурлыгы булганда, дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты документлар белән гаризаны теркәгәннән соң 16 эш көненә кадәр озайтыла.

2.4.2. Таныклыклар Министрлыктан таныклыкларны рәсмиләштерү һәм бирү турындагы күрсәтмәләр алынган көннән башлап ике ай эчендә Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм стихияле бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү эшләре министрлыгы (алга таба – РФ ГТХМ) тарафыннан рәсмиләштерелә.

2.4.3. Таныклык (таныклык дубликаты) һәм (яки) таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турында карар күчермәсен таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар хакында хәбәр ителгән мөрәҗәгать итүчегә тапшыру мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

2.4.3. Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

## 2.5. Закон яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе

2.5.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләрне тапшыра:

Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга таныклык бирү турында гариза. Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән;

Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән торак пунктлар исемлегенә кертелгән торак пунктта яшәү фактын раслаучы документ (торак-эксплуатация идарәләре (торак-коммуналь бүлекләр) архивларыннан өземтә), паспорт өстәлләре белешмәләре, белем бирү учреждениеләре архивлары биргән белешмәләр яисә исемлеккә кертелгән торак пунктларда яшәү фактын раслаучы башка документлар).

Хәрби хезмәткәрләр өстәмә рәвештә, хәрби частьләрнең урнашу урыннарын күрсәтеп, Россия Федерациясе Оборона министрлыгы архивларыннан билгеләнгән тәртиптә бирелгән архив документларын тапшыралар.

Хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзалары өстәмә рәвештә хәрби частьнең хәрби шәһәрчегендә тиешле чорда яшәү (яшәмәү) турында архив белешмәләрен тапшыралар.

Таныклык дубликатын алу өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләрне тапшыра:

Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга таныклык дубликаты бирү турында гариза. Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында китерелгән;

бозылган таныклык, – бозылганы урынына алмаш таныклык алу өчен мөрәҗәгать иткән очракта.

2.5.3. Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

2.5.4. Мөрәҗәгать итүчеләрнең законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итү вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.

2.5.5. Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.

2.5.6. Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Идарә (бүлек) хезмәткәре тарафыннан таныклана.

2.5.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Идарәгә (бүлеккә) шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

2.5.8. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

2.5.9. Гаризаны шулай ук Үзәк бүлекчәсендә белгеч шәхсән кабул иткәндә электрон рәвештә тутырырга мөмкин, аны мөрәҗәгать итүче, электрон рәвештә укыла торган имзадан файдаланып, имзалый.

2.5.10. Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары таләпләренә туры китереп, электрон имза белән кул куелган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итә торган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма

2.6.1. Вәкаләтле органнардан ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәге белешмәләр алына:

Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары аркасында алынган суммар (җыелган) нәтиҗәле нурланыш дозасы турында бәяләмә (гражданин тарафыннан әлеге торак пунктта яшәүчеләргә радиация йогынтысы ясаган атом-төш сынаулары уздырылган көнне үз эченә алмаган чорда Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана торган Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар ителгән торак пунктлары исемлегенә кертелгән торак пунктта яшәгәнлек турында документлар тапшырылган очракта);

югалган таныклыкның табылмавын раслаучы белешмә;

шәхси счетның иминият номеры турында белешмәләр.

2.6.2. Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

2.6.3. Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

2.6.4. Идарә (бүлек) дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүмат тапшыруны яки гамәлләр башкаруны мөрәҗәгать итүчедән таләп итүгә хокуклы түгел;

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торганын да, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган

дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә элегрәк электрон үрнәкләре таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

Идарәгә (бүлеккә) гариза һәм 63-ФЗ һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә документлар (документларның күчермәләрен) тапшыру;

документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерелгән, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булуы;

мөрәҗәгать итүченең яшәү урынына карамаган Идарәгә (бүлеккә) мөрәҗәгать итүе.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан дөрес булмаган (төгәл булмаган) белешмәләрдән торган документларны тапшыру тора.

## 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын яки башка төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

### 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләр күрсәтү исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтләрен күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында да белешмәләр

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

### 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

### 2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.

2.12.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

### 2.13. Дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында мөрәҗәгать итүче гаризасын теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да

2.13.1. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризасы гариза һәм документлар алынган көнне теркәлә.

2.13.2. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

### 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.14.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул

исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) әлеге Регламентның 1.4.2 пунктының 1 пунктчасында каралган мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.14.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объектлардан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектка озата йөри торган этне кертү.

2.14.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) дәүләт хезмәте күрсәтүче органнар һәм оешмалар хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга, башка затлар белән беррәттән, дәүләт хезмәте күрсәтүгә комачаулый торган каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар, шулай ук аудиоконтур күчермәләре булу.

2.14.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән һәркемнең файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәте һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәте күрсәтү (шул исәптән тулы күләмдә) мөмкинлеге яки андый мөмкинлекнең булмавы

2.15.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең файдалана алырлык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Идарәләрнең (бүлекләрнең) бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итәлә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләрен мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон рәвештә алу мөмкинлеге;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтелүе.

2.15.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

белгечләр тарафыннан Регламент бозылуга бәйле прецедентлар (нигезле шикаятьләр) булмавы.

2.15.3. Мөрәҗәгать итүченең Идарәләрнең (бүлекләрнең) белгечләре белән бәйләнешкә керү күләме:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен кирәкле документлар турыдан-туры тапшырылганда – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар почта аша җибәрелгәндә, – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

2.15.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Идарә (бүлек) белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.

2.15.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.

2.15.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкның http://mtsz.tatarstan.ru сайтында, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/) алынырга мөмкин.

2.15.7. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр

Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Идарәгә (бүлеккә), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан Идарәгә (бүлеккә) электрон чыганаклардан файдаланып тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закондагы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш.»;

3 нче бүлектә:

Исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре»;

түбәндәге эчтәлекле 3.10 пункт өстәргә:

«3.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.»;

5 бүлектә:

Исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи

затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карап тикшерү чоры - аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең) мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән чоры бозылганда, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.».